СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Лениногорск ш.

2020 елның 21 февраленнән №7

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү турында» 2016 елның 14 июлендәге 68 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 01 апрелендәге 45-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Лениногорск шәһәре прокуратурасының 2019 елның 03 декабрендәге 02-08-03 номерлы протестын, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү турында» 2016 елның 14 июлендәге 68 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.ТР "ЛМР" муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруны планлаштыру Башкарма комитет тарафыннан эшләү һәм Лениногорск район Советы тарафыннан раслану юлы белән гамәлгә ашырыла: муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программалары). хосусыйлаштырыла торган муниципаль мөлкәтне сату һәм (яисә) мондый мөлкәтне сатучы функцияләрен башкару милекчесе исеменнән оештыру өчен юридик затлар исемлеген**;**

исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә расланган электрон мәйданчыклар операторларына һәм электрон мәйданчыкларның эшләвенә өстәмә таләпләр билгеләү.";

4 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- үз карарлары белән «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы тарафыннан расланган юридик затларга милекче исеменнән Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге хосусыйлаштырыла торган милекне билгеләнгән тәртиптә сатуны һәм (яисә) мондый мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашыруны йөкләргә.»

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе Р.А. Солтановага йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Хөсәенов